ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫАПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2025 ел,28 апрель № 162

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендәТатарстан Республикасы Апас муниципаль районының Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлегенең башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «19173» санын «21091» санына алмаштырырга;

1.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а)елга 15,48 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итүче норматив чикләрендә 27207 сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү;»;

2.2 пунктта «13990» санын «15389» санына алмаштырырга;

2.4 пунктының 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктының 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгы
Иске Йомралы авыл җирлеге Советы рәисе Р.А.Муратов